# Егерме өч ел янәшә



РӘСТӘМ МАЛИКОВ

**Илһам Шакиров! Бу кеше һәр татар өчен иң кадерле заттыр дип беләм. Ул безнең җыр сәнгатен иң югары ноктага күтәргән шәхес, эстрадага Илһам абый күп яңалык китерде.**



Һәр яңалыкны без аның башкаруында ишетә тордык. Аның искиткеч матур тембрлы баритон тавышы, моңлы бай мелизматикалы тавыш йөреше (звуковедение) шәхсән мине малай чакта ук тәэсирләндерә иде. Их, шушы кеше кебек җырлый белсәң иде, дип хыялга чума идем. Әлбәттә, ул җырлаган җырларны пластинка аша тыңлап, кушылып җырлый идем. Чыннан да, Илһам Шакировның тавышы моңарчы ишетелмәгән бер могҗиза бит. Әле дә исемдә, 6 нчы класста укыган вакытта мин район үзешчәннәр смотрында Илһам абый репертуарындагы "Аһ, җырларым!" дигән әсәрне башкарып беренче урын яулап кайткан идем. (Җырның авторлары – композитор А.Ключарев, Ә.Ерикәй сүз.)

Шушы вакыйга миндә җырчы булырга дигән теләкне тагын да ныгытты. Әлбәттә, ул чагында киләчәктә мин шушы кеше белән бергә эшләрмен, хәтта дустанә мөгамәләдә булырмын дип, һич уема да кертми идем. Илһам абый белән якыннан танышу 1971 елда булды. Концерт бригадасы белән ул Минзәләгә килде һәм район мәдәният йортында бер кичтә ике концерт куйды. Бер кичтә ике концертта җырлау ул заман өчен шулай ук бер яңалык иде. Мин шул ике тамашаны да сәхнә артында утырып тыңладым. Ул вакытта мәдәният йортында рәссамбизәүче булып эшли идем. Концерттан соң мәдәният йорты директоры Фазыл абый артистларны үз кабинетына чәйгә чакырды. Мин дә шунда идем. Фазыл абый мине Илһам Шакиров белән шунда таныштырды. Менә бездә дә бар бер җырчы егет, быел Казан музыка училищесына укырга керде, диде. Шуннан соң, пианинода үзе уйнап, Илһам абый мине җырлатып карады, киңәшләрен әйтте. Сәнгать юлында бәхет табуымны теләде. Фәйзи Йосыпов дигән легендар конферансье да бу төркемдә иде. Ул Илһам абыйдан "Туган тел"не җырлавын үтенде. Менә шунда ишеттем инде мин беренче мәртәбә "Туган тел"нең тыелган куплетын:

*И туган тел, синдә булган*
*Иң элек кыйлган догам.*
*Ярлыкагыл дип үзем һәм*
*Әткәм-әнкәмне Ходам!*

Еллар уза торды, мин инде Казан музыка училищесын, аннан соң Казан дәүләт консерваториясен уңышлы тәмамладым. Уфага китеп, сигез ел Башкорт дәүләт филармониясендә эшләп, янә Казанга филармониягә кайттым. Илһам Шакиров ул вакытта сәнгать җитәкчесе иде. Татар дәүләт филармониясендә Илһам абый белән егерме өч ел янәшә эшләргә насыйп булды. Шактый күп җирләрдә бергә гастрольләрдә булырга туры килде шушы даһи җырчы белән. Кайда гына булсак та, Илһам абый янында гел рәхәт була иде. Ул үзе бик юморга оста, тыйнак һәм үтә гади кеше. Безнең белән үз тиңе итеп сөйләшә, киңәшләр бирә. Бергә эшләгән вакытларны мин бик сагынып искә алам. Хәзер инде мин Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында укытам. Филармониягә яшь директор килү сәбәпле, миңа аннан китәргә туры килде, шуңа күрә Илһам абый белән еш очрашып булмый.

Мин аны юбилее белән чын күңелдән котлыйм. Аңа күңел тынычлыгы һәм сәламәтлек, озын гомер телим!